**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ              КАРАР

_____________              № _____

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә Сосновский балтырганын юк итү чаралары турында

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 30.01.2026 ел, № 30/1-700 хатына һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә Сосновский балтырганын юк итү чараларын оештыру максатында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Сосновский балтырганы белән чүпләнгән, эшкәртелергә тиешле мәйданнарны билгеләү буенча комиссия төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. 2026 елга 2027 һәм 2028 елларның план чорына Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш буенча чаралар планын расларга (2 нче кушымта).
3. Актаныш муниципаль районы территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш буенча чаралар планын үтәү буенча тәкъдимнәрне расларга (3 нче кушымта).
4. Җирдән файдаланучыларга, барлык милек формаларындагы учреждение-оешма җитәкчеләренә план чараларын вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә, аларны уздыру буенча хисапны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырырга киңәш итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче              И.Ш. Бариев

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
___________ №__________
3 нче кушымта

2026 елга 2027 һәм 2028 еллар план чорына Актаныш муниципаль районы территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш чаралары планын үтәү буенча тәкъдимнәр

Чүп үләне - Сосновский балтырганы (алга таба-Сосновский балтырганы) белән нәтиҗәле көрәшне оештыру өчен Сосновский балтырганы таралу учаклары территориясендә барлык җаваплы затларның көчләрен туплау һәм комплекслы якын килү зарур.

Сосновский балтырганының вегетатив үзенчәлекләрен исәпкә алып, чаптыру чүп үләннәрен күп тапкырлар кабатлаганда гына үтерә (вегетация өчен 3-5 тапкыр), ә нокталы яки полосалы эшкәртүләр вакытында тулысынча юкка чыкмаганда яңадан чүпләнүгә дучар була.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларын үткәрү өчен җаваплыларга тәкъдим ителә:

1) авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарын, җирләрдән файдаланучы оешмаларны да кертеп, Сосновский балтырганы үсү урыннарын картага төшерергә, Актаныш муниципаль районының һәр торак пунктында Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларын үтәү өчен җаваплыларны күрсәтеп, әлеге белешмәләрне картография материалына язарга;

2) Авыл җирлеге территориясендә, химия чараларын, су саклау һәм табигатьне саклау зоналарында куллануны чикләүне исәпкә алып, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Сосновский балтырганы буенча план эшләргә һәм расларга. Гомуми файдалану урыннарына, социаль һәм белем бирү объектларына аерым игътибар бирергә;

3) гербицидлар куллану тыелмаган территорияләрдә Сосновский балтырганы белән көрәшү өчен химик методны нәтиҗәле куллану. Химик эшкәртүне үткәрү сроклары-массакүләм үсү фазасы (май ахыры июнь башы);

4) Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларын үткәргәндә, иминлек техникасын үтәүне тәэмин итәргә;

5) Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларын үтәүне Сосновский балтырганын юк итү буенча башкарылган эшләрне тапшыру-кабул итү акты белән рәсмиләштерергә.

6) Сосновский балтырганы үсүнең эре учаклары булганда, авыл җирлегендә урнашкан (халык пунктлары җирләре, авыл хуҗ алыгы билгеләнешендәге җирләр, юлларның саклау зоналары), ведомствоара комиссия төзергә, аның составына авыл җирлеге җирле үзидарә органнары, муниципаль район җирле үзидарә органнары, Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларын үтәү өчен җаваплы оешмалар һәм гражданнарны кертергә. Комиссиядә Сосновский балтырганына каршы көрәшнең вакытлары һәм чаралары турында, аны тулысынча юк итүгә юнәлдерелгән карарл ар кабул ителергә тиеш.

7) Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларын үтәү өчен җирле бюджетта акча карарга;

8) Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына һәр торак пунктта җыелышлар (очрашулар) үткәрүне тәэмин итәргә, анда Сосновский балтырганы таралу куркынычы турында, аны вакытында чабу яки башка юк итү ысулларын куллану кирәклеге турында белешмәләр тапшырырга. КФХ башлыклары, оешма җитәкчеләре белән орлыклар өлгерү чорында балтырганны юк итү турында аңлату эшләре алып бару. Мәгълүматны муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга;

9) җаваплы затларга ведомство буйсынуындагы территориядә Сосновский борщевигына каршы көрәш чараларының үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

10) җирдән файдаланучыларга һәм барлык милек формаларындагы учреждение һәм оешма җитәкчеләренә План чараларын вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә, аларны уздыру буенча хисапны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2026 елга 2027 һәм 2028 еллар план чорына Сосновский балтырганына каршы көрәш чаралары планы

| т/б | Чаралар атамасы | Эшләр күләмега | Чараны үтәү вакыты | Чараны уздыру нәтиҗәләре | Чараны үткәрү өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сосновский балтырганы белән чүпләнгән территорияләрне тикшерү, инвентаризация | | Апрель октябрь | Сосновский балтырганын таратуның җыелма мәгълүматын төзү | Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |
| 2 | Сосновский балтырганына каршы көрәш буенча кирәкле чаралар турында халык белән мәгълүмати эш | | март июль | мәгълүматны муниципаль районның Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 3 | Сосновский балтырганына каршы көрәшнең механик ысулын куллану | | апрель октябрь | Сосновский балтырганы тамырларын 10-20 см тирәнлеккә кисү Сосновский балтырганы сабакларын (чәчәк атканчы) чабу, коры үсемлекләрне җыю; тамыр системасын казу | Сосновский балтырганы үсү факты ачыкланган территориядәге авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, җир кишәрлекләреннән файдаланучылар |
| 4 | Сосновский | | май | Үсү учакларына | Җирле |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | балтырганына каршы көрәштә химик ысулны куллану | | октябрь | гербицидлар һәм (яисә) арборицидлар сиптерү; пестицидлар куллану регламентлары таләпләрен җентекләп үтәү | үзидарә органнары, җирдән кулланучы лар |

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
________ №___ 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә Сосновский балтырганы белән чүпләнгән мәйданнарны билгеләү комиссиясе составы

Бариев И.Ш. - комиссия рәисе-Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Сәлимгәрәев Н.Ә.- комиссия рәисе урынбасары - Актаныш районында ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы идарәсе башлыгы;

Мөхәммәтдинов Д.З. - комиссия секретаре - Актаныш районында ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы идарәсенең финанс-икътисад бүлеге башлыгы.

Комиссия әгъзалары:

Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).